**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 гыйнварындагы 126 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 декабрендәге 4607 номерлы**
**«Россия Федерациясе Тикшерү комитетының**
**Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе**
**коллегиясен әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең**
**урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары хәрәкәтен**
**чикләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 22 декабрендәге 4607 номерлы «Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе коллегиясен әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына, 1.1 пунктында «2026 елның 15 гыйнварында 10:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «2026 елның 23 гыйнварында 10:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**